ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2023 г. Заинск № 106

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе, "Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү" буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау турында” Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.01.2023 елның 13 гыйнварындагы под-33/23 номерлы боерыгы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 21 июлендәге 472 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

2.2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 21 июлендәге 472 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 22 мартындагы 142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э. Р. Сәфәргалиев
3-27-42